СОВЕТ СОКУРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422622 с.Сокуры,
ул. Державина, д.12 а
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12 а нчы
йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

35 номерлы 2019 елның 21 октябрендәге

# КАРАР

.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципальрайоны Сокуры авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 октябрендәге 10 номерлы«Җир салымы турында"» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 октябрендәге 10 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 пунктта:

а) 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы җирләргә карата 0,3 %;»

б) 2 пунктчаны төшереп калдырырга;

в) 3 пунктчада «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) сүзләрен өстәргә)";

г) 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

«5) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми

билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата "Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек хуҗалыгын үз ихтыяҗлары өчен алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 % ";

д). 6 пунктчаны төшереп калдырырга

1.2 2 пунктның 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

« - янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары .

Әлеге карарның 2 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән физик затларга ташламалар салым түләүчене сайлау буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган бер җир кишәрлегенә карата бирелә дип билгеләргә.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар салым түләүче тарафыннан салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.»

1.3 4 пунктта «беренче квартал узгач, 5 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал узгач - 5 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал узгач - 5 ноябрьдән дә соңга калмыйча» сүзләре .
Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 5 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.1 һәм 1.2 пунктчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.3 пунктчасы 2021 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә .

4.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда түбәндәге адрес буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырырга: htth://pravo.tatarstan.ru, Лаеш муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: htth://laishevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга...

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

Җирлек башлыгы - Татарстан Республикасы

Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл

җирлеге Советы Рәисе- А.А.Новиков